**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О признании утратившими силу отдельных положений статьи 8 Закона Республики Татарстан «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» и Закона Республики Татарстан «Об организации в Республике Татарстан назначения и осуществления ежемесячной выплаты в связи с рождением (усыновлением) первого ребенка»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
15 декабря 2022 года

**Статья 1**

Признать утратившими силу:

1) абзацы третий – шестой пункта 7 статьи 8 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 12 (II часть); 2005, № 2; 2006, № 2 (I часть); 2007, № 11; 2014, № 6 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2022, № 3 (часть I);

2) Закон Республики Татарстан от 11 апреля 2018 года № 18-ЗРТ «Об организации в Республике Татарстан назначения и осуществления ежемесячной выплаты в связи с рождением (усыновлением) первого ребенка» (Собрание законодательства Республики Татарстан, 2018, № 29 (часть I).

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу с 1 января 2023 года.
2. Гражданам, которым ежемесячное пособие на ребенка в возрасте до 16 лет (на обучающегося в общеобразовательной организации – до окончания им обучения, но не более чем до достижения им возраста 18 лет) назначено до 1 января 2023 года, указанное ежемесячное пособие выплачивается до окончания срока его предоставления.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
23 декабря 2022 года
№ 97-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясының аерым нигезләмәләренең һәм «Татарстан Республикасында беренче бала туугa (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә айлык түләүне билгеләүне һәм гамәлгә ашыруны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 15 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 7 пунктының өченче – алтынчы абзацларын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 3 (I өлеш);

2) «Татарстан Республикасында беренче бала туугa (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә айлык түләүне билгеләүне һәм гамәлгә ашыруны оештыру турында» 2018 елның 11 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 29 (I өлеш).

**2 статья**

1. Әлеге Закон 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. 16 яшькә кадәрге балага (гомуми белем бирү оешмасында белем алучыга – ул укуын тәмамлаганчы, әмма аңа 18 яшь тулганчы гына) айлык пособие 2023 елның 1 гыйнварына кадәр билгеләнгән гражданнарга әлеге айлык пособие аны бирү срогы тәмамланганчы түләнә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ / АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2022 ел, 23 декабрь
№ 97-ТРЗ